**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.06.2015 № 431

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2015 елның 20 июлендә теркәлде, № 2802

**Хезмәттә аерылып торуның хезмәттәге казанышлар һәм уңышлар өчен гамәлгә куелган ведомство билгеләре Татарстан Республикасында “Хезмәт ветераны” исемен биргәндә исәпкә алына торган дәүләт органнарының һәм дәүләт хакимияте органнары исемлегенә кертелгән оешмаларның һәм СССР, РСФСРның, Россия Федерациясенең башка дәүләт органнарының, СССР, РСФСРның, Россия Федерациясенең дәүләт (ведомство) функцияләрен үтәүдә катнашучы (катнашкан) иҗтимагый берләшмәләре һәм оешмаларының Үзәк органнарының хезмәттә аерылып торуның ведомство билгеләре исемлегенә (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Татарстан Республикасында “Хезмәт ветераны” исемен биргәндә исәпкә алына торган хезмәттә аерылып торуның ведомство билгеләре исемлеген раслау турында” 29.06.2012 ел, № 481 боерыгы белән расланган) үзгәрешләр кертү турында**

“Хезмәт ветераны” исемен бирү буенча эшне камилләштерү максатыннан **боерык бирәм**:

Хезмәттә аерылып торуның хезмәттәге казанышлар һәм уңышлар өчен гамәлгә куелган ведомство билгеләре Татарстан Республикасында “Хезмәт ветераны” исемен биргәндә исәпкә алына торган дәүләт органнарының һәм дәүләт хакимияте органнары исемлегенә кертелгән оешмаларның һәм СССР, РСФСРның, Россия Федерациясенең башка дәүләт органнарының, СССР, РСФСРның, Россия Федерациясенең дәүләт (ведомство) функцияләрен үтәүдә катнашучы (катнашкан) иҗтимагый берләшмәләре һәм оешмаларының Үзәк органнарының хезмәттә аерылып торуның ведомство билгеләре исемлегенә (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Татарстан Республикасында “Хезмәт ветераны” исемен биргәндә исәпкә алына торган хезмәттә аерылып торуның ведомство билгеләре исемлеген раслау турында”

29.06.2012 ел, № 481 боерыгы белән расланган) исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта:

кырык дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының “Сугышчан батырлык өчен”;

йөз кырык беренче абзацта “.” тыныш билгесен “;” тыныш билгесенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

СССРның Дәүләт иминлеге комитетының I, II, III дәрәҗә “Бик яхшы хезмәт иткән өчен”;

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең иминлеге өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең “Россия Дәүләт санитария-эпидемия хезмәтенә – 90 ел”;

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының “Суларда һәлак булучыларны коткарган өчен”;

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының “Янгыннарны булдырмаган өчен”;

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының “Маршал Василий Чуйков”;

Россия Федерациясе Югары Суды каршындагы Суд департаментының “Бик яхшы хезмәт иткән өчен”;

Россия Федерациясе Югары арбитраж судының “Россия Федерациясе арбитраж судларына – 20 ел”;

Россия Федерациясе Спорт министрлыгының “Петр Лесгафт”;

Бәйсез Дәүләтләр Берлеге, чит илдә яшәүче ватандашлар, һәм халыкара гуманитар хезмәттәшлек эшләре федераль агентлыгының “Тынычлык, дуслык һәм хезмәттәшлекне ныгыту өчен”;

РФ Физик культура һәм спорт дәүләт комитетының “Россия дәүләт спорт комитетына – 80 ел”;

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең “Казанышлар өчен”;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының “Миналарны зарарсызландырган өчен”;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының “Коткару хакына кыюлык өчен”;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының “Гадәттән тыш шартларда хезмәт иткәндәге казанышлар өчен”;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының “Хезмәттәге батырлык өчен”;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының “Хокук тәртибен ныгытуга керткән өлеш өчен”;

Россия Федерациясе Дәүләт таможня комитетының “Батырлык өчен”;

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының “Хезмәт бурычына тугрылык өчен”;

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының “Батырлык һәм куркусызлык”;

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының “Казанышлар өчен”;

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының “Аерылып торган өчен”;

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының “Тикшерү органнары ветераны”;

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының “Бик яхшы хезмәт иткән өчен”;

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының “Хезмәт иткәндәге тырышлык өчен”;

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының “Булышлык иткән өчен”.”;

2) 2 пунктта:

сиксән сигезенче абзацта “.” тыныш билгесен “;” тыныш билгесенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

Бәйсез Дәүләтләр Берлеге, чит илдә яшәүче ватандашлар, һәм халыкара гуманитар хезмәттәшлек эшләре федераль агентлыгының “Бәйсез Дәүләтләр Берлеге, чит илдә яшәүче ватандашлар, һәм халыкара гуманитар хезмәттәшлек эшләре федераль агентлыгының мактаулы хезмәткәре”;

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең “Росреестрның мактаулы хезмәткәре”;

Россия Үзәк Банкының “Россия Банкы отличнигы”;

СССРның көнбатыш һәм көнчыгыш районнарының күмер промышленносте һәм СССРның ягулык предприятиеләре төзелеше министрлыгының “Мактаулы шахтер”;

Россия Федерациясе Ягулык һәм энергетика министрлыгының “Мактаулы нефтьче”.”;

3) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Оборона министрлыгы Космос гаскәрләре командующиеның истәлек билгесе;

егерменче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының I, II, III, IV, V дәрәҗә "Диңгез транспортында авариясез эшләгән өчен";

егерме алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының шәһәр электр транспорты хезмәткәрләре өчен I дәрәҗә "Авариясез эшләгән өчен";

утыз җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының "Россиянең мактаулы юстиция хезмәткәре";

ике йөз илле беренче абзацта ", күкрәк билгесе белән бүләкләү" сүзләрен төшереп калдырырга;

ике йөз илле өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Элемтә һәм мәгълүматлаштыру дәүләт комитетының "Мактаулы радист";

ике йөз илле тугызынчы абзацта “.” тыныш билгесен “;” тыныш билгесенә алмаштырырга;

йөз уникенче, йөз егерме өченче, йөз егерме дүртенче, йөз егерме бишенче һәм йөз егерме алтынчы абзацларны көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының "Гражданнар авиациясенә - - 85 ел";

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының "Россиянең МЧС ветераны";

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының "Коткаручы хәрби формированиеләр отличнигы";

Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының "Россия Федерациясенең дәүләт урман сагында хезмәт итүнең X еллыгы";

Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының "Россия Федерациясенең дәүләт урман сагында хезмәт итүнең XX еллыгы";

Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының "Россия Федерациясенең дәүләт урман сагында хезмәт итүнең XXX еллыгы";

Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының "Россия Федерациясенең дәүләт урман сагында хезмәт итүнең XL еллыгы";

Россия Урман хуҗалыгы федераль хезмәтенең "Россия Федерациясенең дәүләт урман сагында хезмәт итүнең X еллыгы";

Россия Урман хуҗалыгы федераль хезмәтенең "Россия Федерациясенең дәүләт урман сагында хезмәт итүнең XX еллыгы";

Россия Урман хуҗалыгы федераль хезмәтенең "Россия Федерациясенең дәүләт урман сагында хезмәт итүнең XXX еллыгы";

Россия Урман хуҗалыгы федераль хезмәтенең "Россия Федерациясенең дәүләт урман сагында хезмәт итүнең XL еллыгы";

СССР Мәдәният министрлыгының һәм Мәдәният хезмәткәрләре профсоюзының "Үзешчән сәнгать иҗатындагы уңышлар өчен";

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының "Шәфкать";

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының "Социаль хезмәт өлкәсе отличнигы";

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының "Сәламәтлек саклау отличнигы";

Россия Федерациясе Спорт министрлыгының "Физик культура һәм спортны үстерүдәге казанышлар өчен";

Россия Федерациясе Спорт министрлыгының "Физик культура һәм спорт отличнигы";

Бәйсез Дәүләтләр Берлеге, чит илдә яшәүче ватандашлар, һәм халыкара гуманитар хезмәттәшлек эшләре федераль агентлыгының “Дуслык һәм хезмәттәшлек өчен”;

СССРның көньяк районнарында төзелеш министрлыгының "СССРның көньяк районнарында төзелеш министрлыгының социалистик ярыш отличнигы";

"РСФСР Автомобиль транспорты министрлыгының социалистик ярыш отличнигы";
"РСФСР Торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының социалистик ярыш отличнигы";
"РСФСР Җиңел промышленность министрлыгының социалистик ярыш отличнигы";
"РСФСР Автомобиль юллары министрлыгының социалистик ярыш отличнигы";
РСФСР Елга флоты министрлыгының "Елга флоты министрлыгының социалистик ярыш отличнигы";
"РСФСР Гражданнар торагы төзелеше министрлыгының социалистик ярыш отличнигы";
"РСФСР Төзелеш материаллары промышленносте министрлыгының социалистик ярыш отличнигы";
"РСФСР Социаль тәэминат министрлыгының "РСФСРның социалистик ярыш отличнигы" һәм "РСФСРның социаль тәэминат отличнигы";
"РСФСР авыл хуҗалыгы социалистик ярышы отличнигы";
"СССР Күмер промышленносте министрлыгының социалистик ярыш отличнигы";
СССР союзы Элемтә министрлыгының "СССР элемтә социалистик ярышы отличнигы";
"СССР Азык-төлек резервлары министрлыгының социалистик ярыш отличнигы";
"СССР Авыр Промышленность Социалистик Ярышы Отличнигы";
"РСФСР Социалистик Ярыш Отличнигы";
Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең “Бик яхшы эшләгән өчен”;
Россия Үзәк Банкының “Россия Банкында бик яхшы эшләгән өчен”;
Космос федераль агентлыгының Циолковский Билгесе;
Космос федераль агентлыгының Королев Билгесе;
Космос федераль агентлыгының Гагарин Билгесе;
Космос федераль агентлыгының "Космик стартларны тәэмин иткән өчен";
Космос федераль агентлыгының "Космик эшчәнлеккә булышлык иткән өчен";
Космос федераль агентлыгының "Космонавтика өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек өчен";
Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының "Россия мәдәниятенә керткән өлеш өчен";
Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының "Аучылык хуҗалыгының мактаулы хезмәткәре";
Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының "Аучылык хуҗалыгы отличнигы";
Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең иминлеге өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең “Роспотребнадзорның мактаулы хезмәткәре”;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының "Гадәттән тыш шартларда хезмәт иткәндә аерылып торган өчен";

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының "Полиция отличнигы";

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының "Эчке эшләр министрлыгына булышлык иткән өчен";

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының "Сугыш хәрәкәтләрендә катнашучы";

"Россия Федерациясе Тикшерү комитетының мактаулы хезмәткәре";

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының "Тикшерү органнары отличнигы";

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының "Иң яхшы тикшерүче";

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының "Законга хезмәт иткән өчен";

Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының I, II, III, IV һәм V дәрәҗә "Елга транспортында авариясез эшләгән өчен";

Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының "Тимер юл транспортында авариясез эшләгән өчен".";

4) дүртенче сносканы төшереп калдырырга.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**